КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 24 июль г.Казань № 546

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында территорияне комплекслы үстерү турындагы карарларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле юридик затны билгеләү турында» 2021 ел, 11 сентябрь, 860 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Республика Татарстан Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында территории комплексы үстерү турындагы карарларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле юридик затны билгеләү турында» 2021 ел, 11 сентября, 860 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 4 сентябрь, 1065 нче, 2024 ел, 10 сентябрь, 758 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында территорияләрне комплексы үстерү операторларын билгеләү турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында территорияләрне комплексы үстерү турындагы карарларны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче территорияләрне комплексы үстерү операторлар итеп түбәндәге юридик затларны билгеләргә:

Дәүләт торак фонды - Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды;

Намуссыз төзүчеләр гамәлләреннән зыян күргән затларга ярдәм итү республика фонды.».

2. Намуссыз төзүчеләр гамәлләреннән зыян күргән затларга ярдәм итү республика фондына гамәлгә кую документларына тиешле үзгәрешләр кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин